ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
(V чакырылыш)

# КАРАР

№ 7 Кече Урыссу ав. «03» апрель 2026 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының аерым караларының үз көчләрен югалтуын тану турында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 273-ФЗ санлы, 2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль законнар нигезендә, Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм үз көчләрен югалткан дип тану турында»гы 1009 санлы Указы белән,татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау турында", шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүе хакында» 18 санлы карарын;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 сентябрендәге «Ютазы муниципаль районының « Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының « Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль бурычларны биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы бәйләнешләр турында белешмәләрне урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тапшыру тәртибен раслау турында»гы 4 санлы карарын;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2021 елның 3 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклары турында белешмәләр бирү турында һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 8 санлы карарын;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә

(http://pravo.tatarstan.ru; 2013 елның 17 декабрендәге Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталын урнаштыру адресы буенча http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Н.С.Рәфыйков